**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
ЧЕРЕМШАНСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН
**ГЛАВА ШЕШМИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ**

ул.Комарова, д.14, с.Шешминская Крепость, 423104

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
ЧИРМЕШӘН МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ
**ШЕШМИНКА АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШЛЫГЫ**

Комаров урамы, 14 йорты, Шешминка Крепосте авылы, 423104

тел./факс(84396) 2-36-54 email: Shesh.Cmn2@tatar.ru

---

**№123** **17 июнь 2025 ел**

**Татарстан Республикасы
Чирмешән муниципаль районының
Шешминка авыл җирлеге Советы
карары**

**Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының «Шешминка авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 44 статьясы, «Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2016 елның 28 декабрендәге Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 7 статьясы, Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының «Шешминка» авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Уставының 85,86,87 статьялары нигезендә Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының Шешминка авыл җирлеге Советы КАРАР КЫЛДЫ:

1. Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының «Шешминка авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге уставына түбәндәге үзгәрешләрне һәм өстәмәләрне кертергә:

1.1. «Шешминка авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең исеме һәм хокукый статусы» 1 статьяның 2 пунктын яңа редакциядә бәян итәргә: «2. Муниципаль берәмлекнең рәсми исеме - Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының «Шешминка авыл җирлеге» (алга таба текст буенча – Җирлек), кыскартылган исеме - «Шешминка авыл җирлеге».

1.2. 5 статьяда:

- 1 өлешнең 8 пунктына түбәндәге эчтәлекле 3 абзац өстәргә: «- «Шәхси ярдәмче хуҗалык турында» 2003 елның 7 июлендәге 112-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә гражданнар алып бара торган шәхси ярдәмче хуҗалыкларны хуҗалык кенәгәләрендә исәпкә алуны гамәлгә ашыру».

- 1 өлешнең 9 пунктын яңа редакциядә бәян итәргә: «9) җирлек территориясен төзекләндерү кагыйдәләрен раслау, җирлек территориясен төзекләндерү

кагыйдәләрен, социаль, инженерлык һәм транспорт инфраструктуралары объектларыннан һәм күрсәтелә торган хезмәтләрдән инвалидларның файдалана алуын тәэмин итү таләпләрен үтәүдән гыйбарәт булган төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контрольне гамәлгә ашыру, күрсәтелгән кагыйдәләр нигезендә җирлек территориясен төзекләндерүне оештыру».

- 21 пунктны үз көчен югалткан дип танырга.

1.3. 6 статьяга түбәндәге эчтәлекле 3 пункт өстәргә: «Җирле үзидарә органнары Россия Федерациясенең тапшырылган вәкаләтләрен, Татарстан Республикасы вәкаләтләрен тиешле вәкаләтләрне гамәлгә ашыруны финанс белән тәэмин итү максатларында җирле бюджетларга бирелгән субвенцияләр чикләрендә гамәлгә ашырган өчен җаваплы булалар».

1.4. 7 статьяда «Татарстан Республикасы законнары» сүзләреннән соң «Җирле үзидарә турында» сүзтезмәсен төшереп калдырырга.

1.5. Түбәндәге эчтәлекле 7.1 статья өстәргә: «7.1 Статья. Район җирле үзидарә органнарының халыкара һәм тышкы икътисадый элемтәләре

1. Җирлекнең җирле үзидарә органнары халыкара һәм тышкы икътисадый элемтәләрне түбәндәге рәвешләрдә гамәлгә ашыралар:

1) чит дәүләтләрнең дәүләт территориаль, административ-территориаль һәм муниципаль берәмлекләре вәкилләре белән халыкара һәм тышкы икътисадый элемтәләр өлкәсендә очрашулар, консультацияләр һәм башка чаралар үткәрү;

2) чит дәүләтнең җирле үзидарә органнары белән халыкара һәм тышкы икътисадый элемтәләрне гамәлгә ашыру турында килешүләр төзү (алга таба - килешү);

3) махсус шушы максат өчен төзелгән органнар вәкаләтләре кысаларында муниципальара хезмәттәшлек өлкәсендә халыкара оешмалар эшчәнлегендә катнашу;

4) муниципалитетара хезмәттәшлекнең халыкара программалары проектларын эшләүдә һәм гамәлгә ашыруда катнашу;

5) Россия Федерациясенең халыкара шартнамәләре, федераль законнар, Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актлары һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә җирле үзидарә органнарының халыкара һәм тышкы икътисадый элемтәләр өлкәсендәге башка вәкаләтләре.

2. Халыкара һәм тышкы икътисадый элемтәләр «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законында билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты белән килештереп, җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү максатларында җирлекнең җирле үзидарә органнары тарафыннан гамәлгә ашырыла.

3. Җирлек җирле үзидарә органнарының халыкара һәм тышкы икътисадый элемтәләрен гамәлгә ашыру турындагы килешү «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законында билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан вәкаләт бирелгән республика башкарма хакимият органы тарафыннан теркәлергә тиеш.

Вәкаләтле орган тарафыннан җирле үзидарә органнарының халыкара һәм тышкы икътисадый элемтәләрен гамәлгә ашыру турындагы килешүләрне теркәү мондый килешүләрнең үз көченә керүенең мәҗбүри шарты булып тора.

4. Җирле үзидарә органнарының халыкара һәм тышкы икътисадый элемтәләрен гамәлгә ашыру турында имзаланган килешүләр әлеге уставның 77 статьясында билгеләнгән тәртиптә басылып чыгарга (халыкка җиткерелергә) тиеш».

1.6. 11 статьяның 7 өлешендәге 2 абзацында «Суд билгеләгән җирле референдум Җирлек сайлау комиссиясе тарафыннан оештырыла,» сүзтезмәсен «Суд билгеләгән җирле референдум Муниципаль сайлаулар һәм җирле референдум үткәрү буенча сайлау комиссиясе тарафыннан оештырыла,» дип бәян итәргә.

1.7. 13 статьяда:

- 5 өлештә «Җирлек сайлау комиссиясендә» сүзтезмәсен «Муниципаль сайлаулар һәм җирле референдум уздыру буенча сайлау комиссиясе» дип бәян итәргә;

- 8 өлештә «Җирлек сайлау комиссиясе» сүзтезмәсен «Муниципаль сайлаулар һәм җирле референдум уздыру буенча сайлау комиссиясе» дип бәян итәргә;

- 12 өлештә «Җирлек сайлау комиссиясе» сүзтезмәсен «Муниципаль сайлаулар һәм җирле референдум уздыру буенча сайлау комиссиясе» дип бәян итәргә.

1.8. 32 статьяның 1 өлешендә «Җирлек сайлау комиссиясе» сүзтезмәсен «Муниципаль сайлаулар һәм җирле референдум үткәрү буенча сайлау комиссиясе» дип бәян итәргә.

1.9. 33 статьяда:

- 1 өлешнең 5.1 пунктын яңа редакциядә бәян итәргә: «Җирлекне социаль-икътисадый үстерү стратегиясен раслау».

- 1 өлешнең 15 пунктын үз көчен югалткан дип танырга.

- 1 өлешнең 27 пунктын үз көчен югалткан дип танырга.

- 1 өлешнең 33 пунктын бәян итәргә: «33) муниципаль хокукый актларны халыкка җиткерү, рәсми мәгълүматны җирлек халкына җиткерү өчен матбугат массакүләм мәгълүмат чарасын һәм (яисә) челтәр басмасын булдыру».

1.10. 49 статьяда:

- 1 өлештә 8 һәм 10 абзацларны үз көчләрен югалткан дип танырга.

- 6 өлештә:

- 2 абзацны яңа редакциядә бәян итәргә: «төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контрольне гамәлгә ашыра, аның предметлары җирлек территориясен төзекләндерү кагыйдәләрен, социаль, инженерлык транспорт инфраструктуралары объектларыннан һәм күрсәтелә торган хезмәтләрдән инвалидларның файдалана алуын тәэмин итү таләпләрен үтәүдән гыйбарәт, күрсәтелгән кагыйдәләр нигезендә җирлек территориясен төзекләндерүне оештыра;».

- 3 һәм 10 абзацларны үз көчләрен югалткан дип танырга.

- 8 өлешкә түбәндәге эчтәлекле 2 абзац өстәргә: «- «Шәхси ярдәмче хуҗалык турында» 2003 елның 7 июлендәге 112-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә гражданнар алып бара торган шәхси ярдәмче хуҗалыкларны хуҗалык кенәгәләрендә исәпкә алу вәкаләтләрен гамәлгә ашыра».

1.11. 69.1 статьяның 2 өлешендәге 17 пунктын үз көчен югалткан дип танырга.

1.12. VII бүлекне үз көчен югалткан дип танырга.

1.13. 73.1 статьяны яңа редакциядә бәян итәргә «1. Җирлек милкендә булырга мөмкин:

1) «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон белән билгеләнгән җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен билгеләнгән мөлкәт;

2) федераль законнарда һәм Россия Федерациясе субъектлары законнарында билгеләнгән очракларда Җирлеккә тапшырылган аерым дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән мөлкәт, шулай ук әлеге Федераль законның 15 статьясындагы 4 өлешендә каралган тәртиптә Җирлеккә тапшырылган аерым вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән мөлкәт;

3) җирлек Советының норматив хокукый актлары нигезендә җирле үзидарә органнары һәм җирле үзидарәнең вазыйфаи затлары, муниципаль хезмәткәрләр, муниципаль предприятиеләр һәм учреждениеләр хезмәткәрләре эшчәнлеген тәэмин итү өчен билгеләнгән мөлкәт;

4) хәл итү хокукы федераль законнар белән җирле үзидарә органнарына бирелгән һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләләргә кертелмәгән мәсьәләләрне хәл итү өчен кирәкле мөлкәт;

5) 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 14 статьясындагы 3 өлеше нигезендә җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен билгеләнгән мөлкәт, шулай ук әлеге Федераль законның 17 статьясындагы 1 һәм 1.1 өлешләре нигезендә җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән мөлкәт.

2. Җирлекнең әлеге статьяның 1 өлеше таләпләренә туры килми торган мөлкәткә милек хокукы барлыкка килгән очракларда күрсәтелгән мөлкәт яңадан профильләштерелергә (мөлкәтнең максатчан билгеләнеше үзгәрергә) йә читләштерелергә тиеш. Мондый мөлкәтне читләштерү тәртибе һәм сроклары федераль закон белән билгеләнә».

1.14. 73.1 статьяга түбәндәге эчтәлекле 4 өлеш өстәргә: «4. Җирле үзидарә органнары Россия Федерациясенең электр энергетикасы турындагы законнарында билгеләнгән очракларда, тәртиптә һәм шартларда муниципаль милектәге, система барлыкка китерүче территориаль челтәр оешмасына яисә Россия Федерациясе субъекты чикләрендә эш итүче территориаль челтәр оешмасына электр челтәре хуҗалыгы объектларын түләүсез биләүгә һәм файдалануга тапшыруны гамәлгә ашыралар».

1.15. 77 статьяда:

- 1 өлешне яңа редакциядә бәян итәргә: «1. Бюджет проекты чыгым йөкләмәләрен финанс белән тәэмин итү максатларында социаль-икътисадый үсеш фаразы нигезендә төзелә».

- 6 өлешне яңа редакциядә бәян итәргә «6. Җирле бюджет проекты Россия Федерациясе Бюджет кодексы һәм җирлек Советының аның таләпләрен үтәп кабул ителә торган муниципаль хокукый актлары нигезендә җирлек башкарма комитеты билгеләгән тәртиптә төзелә».

1.16. 79 статьяны яңа редакциядә бәян итәргә: «1. Муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алулар дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алулар өлкәсендә контракт системасы турындагы Россия Федерациясе законнары нигезендә гамәлгә ашырыла.

2. Муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алулар җирле бюджет акчалары исәбеннән гамәлгә ашырыла»

1.17. 80 статьяда:

- 2 өлештә «25.1 статьясындагы 1 өлешенең 4 пунктына» сылтаманы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003

елның 6 октябрендәге №131-ФЗ Федераль законның 25.1 статьясындагы 1 өлешенең 4.1 һәм 4.3 пунктларына» сылтамага алмаштырырга.

2. Әлеге карарны законнарда билгеләнгән тәртиптә дәүләт теркәвенә җибәрергә.

3. Әлеге карарны дәүләт теркәвенә алганнан соң рәсми хокукый порталда бастырып чыгарырга (pravo.tatarstan.ru) һәм Чирмешән муниципаль районының Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштырырга.

4. Әлеге карар «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131 - ФЗ номерлы Федераль законның 44 статьясындагы 8 өлеше, Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы «Шешминка авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 87 статьясындагы 2 өлеше нигезләмәләрен исәпкә алып, рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Татарстан Республикасы
Чирмешән муниципаль районы
Шешминка авыл җирлеге
башлыгы, Совет рәисе: А.В.Сидоров